МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.12.2022 Казан ш № 1082

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы боерыгы белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль яклау өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №395, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, 15.05.2018 №367, 24.09.2018 №897, 21.02.2019 №129, 19.04.2019 №285, 10.09.2019 №688, 14.11.2019 №1007, 05.02.2020 №65, 08.05.2020 №289, 14.07.2020 №515, 28.10.2020 №764, 30.03.2021 №171, 21.05.2021 №331, 17.08.2021 №591, 27.10.2021 №791, 25.04.2022 №306 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) боерыгы белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 7 декабрендәге 1082 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы боерыгы белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.2.2 пунктында «, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.3 һәм 2.3.4 пунктлары белән тулыландырырга:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап ун эш көне эчендә күрсәтелә.

Юлга айлык акчалата түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

2.4.2 пунктны көчен югалткан дип танырга;

2.6.1 пунктның җиденче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды бүлекчәсе» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган белешмәләр:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (2023 елның 1 гыйнварыннан – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрдан);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан);

торак урынын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (җирле үзидарә органнарыннан);

542 номерлы Нигезләмә кушымтасында төрләренең исемлеге күрсәтелгән

керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарыннан);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарыннан);

опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарыннан);

шәхси счетның иминият номеры турында мәгълүматлар (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (2023 елның 1 гыйнварыннан – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булмавы турында (Федераль салым хезмәтеннән);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүенең гамәлдә булуын раслау турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

үлем турында (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешү (аерылышу) турында (Федераль салым хезмәтеннән);

паспортның гамәлдә булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.»;

2.11.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11.1. Гариза һәм документлар килгән көнне.»;

2.12.4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;»;

2.13.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;»;

2.14.1 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыннары аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.»

3 бүлектә:

3.1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.»;

3.3.1 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм

портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (2023 елның 1 гыйнварыннан – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре (түләүләрнең булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.

3.4.2. Юлга айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаганда, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне һәм документларны сората:

Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Үзәк бүлекчәсенең ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (2023 елның 1 гыйнварыннан – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

542 номерлы Нигезләмә кушымтасында төрләренең исемлеге күрсәтелгән керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

шәхси счетның иминият номеры турында мәгълүматлар (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (2023 елның 1 гыйнварыннан – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында, бала тууын чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәү очрагыннан тыш (Федераль салым хезмәтеннән);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

опека (попечительлек) билгеләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән яшәү урыны буенча теркәлүенең гамәлдә булуын раслау турында белешмәләр (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

мөрәҗәгать итүченең күчемсез мөлкәте булуы турында белешмәләр (Росреестрдан);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

мөрәҗәгать итүчедә транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары булуы турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

үлем турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешү (аерылышу) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

паспортның гамәлдә булуы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш итеlә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары

нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.9 пунктында «, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

Регламентка 1 нче кушымтада «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ____________________» сүзләрен
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында шәхси кабинет аша _______________»
«әйе» дип күрсәтелә яки сызык куела»
сүзләренә алыштырырга.

5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә

билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә токкан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди
ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге»
ДКУ №___ бүлекчәсенә
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,____________________________________________________________,
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
яши торган адрес: _____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)
_____________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,
_____________________________________________________________________,
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________________

юлга айлык акчалата түләү ______________ №____________

(карар датасы) (карар номеры)
билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарда җибәрелгән.

Юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр алуга риза:
язмача ________________________________
почта адресы буенча
түбәндәге телефонга смс-хәбәр итеп ________________________________________
телефон номеры
___________________электрон почта адресына электрон документ формасында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында шәхси кабинет аша ______________
(«әйе» дип күрсәтелә яки сызык куела»)
сүзләренә алыштырырга.

Мөрәҗәгать итүче:________________________ _________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме) (имзасы)»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.